*Нурмиева Г. В.*

# НУРМИЕВА Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР» РОМАНЫНДА МӘГЪРИФӘТЧЕЛ ИДЕЯЛӘРНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

XX гасыр башы татар әдәбиятында әйдәп баручы оппозиция булып XIX гасырдан мирас булып калган мәгърифәтчелек дөнья сурәте тора. Чөнки яңа гасырдагы кәеф-теләкләр, өмет-ышанычлар күп кенә яссылыкларда җәмгыятьне яңарту, кешене камилләштерү максаты куеп формалашкан мәгърифәтчелек хәрәкәте белән якын. Мәгърифәтчелек ноктасыннан караганда, тарихи һәм иҗтимагый үсештә кешеләрнең аңы зур роль уйный, шуңа күрә мәгърифәтчелек наданлыкка,әхлаксызлыкка, дини фанатизмга каршы көрәш ача. Бу көрәш гасыр башы татар мәдәниятендә этәргеч көч урынын били. Мәгърифәтчелек күтәргән күп кенә идеяләр татар җәмгыяте өчен бик тә актуаль булып кала.

“Яшь йөрәкләр” романының буеннан-буена “мохит” сүзе кабатлану, геройларның һәрберсе язмышына карата диярлек хикәяләүче бәяләрендә шушы каршылыкны калкытып кую күзәтелә. “ Назик җанлы вә хәссас йөрәкле адәмнең табигате вә табигый мәелләре белән эчендәге яшәдеге мохит арасында башкалык, дошманлык булса, аның хәяте мәңгелек трагедия эченә ташланмыштыр!”; “Кыскарак әйткәндә, язмыш аны авылга ташласа да, аның җаны, аның хәяте, бигрәк тә эчке дөньясы бөтенләй икенче галәмнең, икенче куәтләрнең тәэсиренә бирелде, вә шул хәлләр Мәрьям белән мохитне бер-беренә каршы куй-

ды”. Зыя “мохитнең мәгънәсез рамкаларын күрә килә, алар көннән-көн арта бара иде” һ.б.

Оппозициягә чыгарылган төшенчәне аңлатып, Г.Ибраһимов болай яза: ”... Мохит вә табигать! Болар һәркемнең хәятында иң зур рольләрне үзләренә алалар. Без яхшы булу,тырышу,тәрбия ителү,теләк вә ирадә хакында сөйлибез. Ләкин бик күп тугрыда, бик күп бәндәләр хакында болар буш сүзләр генә булып кала. Бер адәмнәр мохиткә җиңелү,язмышны үзләре теләгән якка борып җибәрәләр. Ләкин болар- Тәңренең артык мөстәсна коллары. Алар меңгә, миллионга түгел, ничә йөз миллионнарга бер генә, ничә гасырларда бер мәртәбә бичара адәмнәрнең артык буш хәятына бер яңалык, бер байлык бирү өчен генә җибәреләләр...Әмма калганнары,шул мөстаснә даһилардан башкалары,гомер буена мохит вә язмышның колы булалар. Язмыш ни куша, алар шуны кыла; мохит ни сөйли,шул канун була; мохитнең биргән тәэсире аларга табигать булып китә”. Кеше мохиттә яши, мохиттән азат була алмый дигән фәлсәфә әсәрнең башлангыч уйланмасын тәшкил итә. Дөрес, чыгарма төсендә әдип бик сирәк кешеләрнең уз язмышларын үзгәртә алуын әйтә, ләкин боларның гадәттән тыш кеше икәнлекләрен дә искәртергә онытмый.

Романда сурәтләнгән геройлар язмышы мохиттән азат булырга омтылыш белән бәйләнгән. Мисалга төп сюжет сызыкларының берсен тәшкил иткән Зыя- Мәрьям мәхәббәтенә мөрәҗагать итик. Алар арасында хис туу ук автор тарафыннан мохиткә бәйле аңлатылыш таба: “... Мәрьямгә бу мохиттә Зыядан башка иптәш булырга мөмкин түгел иде”,”Зыя белән бергә булу аның нәзакәтенә тими, аны үзенең хәраменнән теге тупас дөньяга чыгарга мәҗбүр итми...” Яшьлек вакытына аяк басуга, мәхәббәткә мохит каршы куела: “Алар хәзер бала түгел. Аларның әүвәлге шикелле ике дус рәвешендә бергә уйнавы, бергә йөрүе, хәтта күрешү, сөйләшүе дә мохит тарафыннан зур гөнаһка санала – алар бер-береннән качарга, хәтта карашмаска да тиеш, чөнки гөнаһ. Алар яшь. Аларда язмышның бу агымына каршы барырлык куәт юк. Алар мохитнең сөйләгәненә буйсыналар, язмышның шул агымына ятып, бер-береннән тәмам, тәмам өзеләләр, ераклашалар”;”Әчләрендә мөбһәм бер тойгы бар. Ул бер-беренә якынлыкны тели. Ләкин мохит аңа “ярамый” ди”.

Мохитнең Аллага тәңгәл тугеллеге автор тарафыннан

Зыяның Тәңре белән сөйләшү өзегендә бик ачык белдерелә: “Синең үзеңнән бер чаткы булган җаннарыбыз бернәрсә тели; безнең йөрәгебез табигатькә тәэсир ала; музыканы гашыйкларның зикере кебек тоя; безгә хәят кирәк, безгә ирек кирәк; безенң күңелләребез син үзең җир йөзенә тараткан надир мәгъбүдләр- матурлар, матур җаннар, гали күңелләр каршысында сәҗдә итәргә тели,- бу теләкләрнең барын син үзең биргәнсең. Ләкин мохит моңа каршы бара”. Бүген шактый каршылыклы кабул ителә торган фәлсәфә болай яңгырый: мохитнең тар рамкаларыннан бары тик түбәнгә төшеп кенә котылырга мөмкин.

Әсәрдә кешегә каршы куелган мохит - күпмедер күләмдә трансцендентальлеккә ия төшенчә. Ул кешене әйләндереп алган тирәлеккә дә, җәмгыятькә дә тәңгәл түгел. Мәгънәдәш сүз төсендә язучы “язмыш”ны файдалана. Романның иң башында китерелгән, әсәрне серле ясаучы ике төш- төш эчендәге төш шушы мәгънәгә өстенлек бирә. Төштә Мәрьям киләчәктә булачак хәлләрне: Зыяның солдатка алынуын, Фәхринең ире булганын, үзенең аны үтерүен, Зыя белән тиңсез мәхәббәтләрен, шуны югалтуларын күрә. Димәк, болар – язмышка язылган, булырга тиешле хәлләр. Төш эчендә авторның алда әйтeләчәк фәлсәфи фикерләре дә белдерелә. Яшәүнең чиклелеге китергән газапны ислам өйрәтүе җиңә, ди автор. Бу фикер Зыяны күмү вакыйгасы белән кисешә.

Төштә китерелгән, Мәрьямнең револьвер алганнан соңгы халәтен тасвирлау тагын бер фикерне ныгыта: язмышны үзгәртү теләге – иң көчле теләк, иң олы омтылыш. Бу алга таба күп геройлар тормышы мисалында кабатланачак.

Өченче фикер мәхәббәтнең – олы бәхет, яраткан кешенең Алла дәрәҗәсендәге кадерле зат булуын белдерә: “...бу сәҗдә гашыйк күңелнең гомер барынча мәгъбүд итеп килгән “җәмал” алдында бер самими табынуыннан гыйбарәт иде”.

Шулай итеп, Г.Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романы (1912) XX йөз башында иҗат ителгән олы эпик жанр үрнәкләре арасында фәлсәфи характерлы булуы белән аерылып тора. Гомумән, әсәр бик тә үзенчәлекле, татар прозасы фонында яңалык булган күп хасиятләргә ия. Романда психологизм тудыру алымнары буларак файдаланылган аң агышы,төшләргә күпләп мөрәҗәгать итү, кешенең озак вакытка сузылган чиктәш халәтен тасвирлау аны реальлек чикләреннән алып чыга.

Әдәбият кайчан барлыкка килсә, андагы фәлсәфи фикерләү – гомумиләштерүгә омтылу да шул вакыттан ук ярала. Фәлсәфи әдәбият туу гомумән “кеше акылының образлы - эмоциональ формада яшәешнең иң катлаулы сорауларына җавап бирү омтылышы белән аңлатыла.

Ф. Шиллерның мәгърифәтчелек характерындагы эстетикасына Кант фәлсәфәсе зур йогынты ясый. Шиллер кеше аңын-акылын камилләштерүнең мөһимлеге һәм әхлак тәрбияләү өчен сәнгатьне файдалану хакында сүз алып бара. Бу идея мәгърифәтчелекнең төп принципларының берсенә әверелә. Кешедәге табигыйлекне әһәмиятле санау, акыл көчен файдаланып камилләшүгә, ирекле акылның яшәештәге барлык кануннарны танып беләчәгенә ышану шулай ук мәгърифәтчелекнең нигез баганаларыннан була. И.Г. Гердер хезмәтләреннән юл алган һәр халыкның үзенчәлекле тарихи һәм мәдәни үсеш юлы кичерүе турындагы концепцияне файдалану өчен дә XX йөз башы татар мәдәниятендә шартлар өлгереп җитә. Болар һәм башка бик күп мәгърифәтчел карашлар гасыр башы фәлсәфи әдәбиятында яңа үсеш ала.

XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләрнең күпләп язылা башлавы милли иҗтимагый андагы үзгәрешләр белән бәйләнгән.

Романда милли фәлсәфәгә шактый киң урын бирелә, ул Зыя образы белән бәйле. Романтик герой Зыя музыкага гашыйк, көйне нечкә тоемлаучы итеп сурәтләнә. Үз заманында Г.Гобәйдуллин Зыя образын безнең мохиткә генә формалаша алырлык тип дип атый, аның фәлсәфәсен руссочы карашлар белән янәшә куя. Шул ук вакытта Зыяның “зәгыйфь, хатыннар табигатьле мәңгелек трагедия әһеле” булуын да җәмгыять- мохиттән күрә. Ягъни, татар җәмгыятенең нечкә күңелле, рухи бай, талантлы яшьләр җитештереп тә, аларга үз сәләтләрен милләт файдасына хезмәткә куярлык шартлар тудырылмау ассызыклана.

Бер яктан, Г.Ибраһимов татар милләтенең хәлен шулай ук мохит чикләреннән чыга алмаган бердәмлек буларак бәяләп уза. Сәлим авызыннан мондый сүзләр әйттерелә: “... Татар дисезме, төрек дисезме, ул милләт туган, үскән, яшәгән. Моның артыннан картлык килү, аннан соң әҗәле табигыйның җитүе дә канун илаһидан; ачыграк әйтсәм, татар ашын ашаган, яшен яшәгән; инде картаеп хәле беткән; хәзер ул әҗәле табигыйсын көтә”.Шул рәвешле, татар милләте кояш баешына бара, диелә. Зыя исә

- шушы язмышны, мохитне үзгәртү юлын тапкан кеше. Ул музыканың көчен болай бәяли: “Улмы? Җан бирә! Җан бирә! Үлгән йөрәкне тергезә! Халыкка үзлеген, үзенең дөньяда барлыгын исенә төшерә, ул безне канатландыра”. Шулай итеп, Г.Ибраһимовның әдәби һәм фәнни иҗатының буеннан- буена сузылып барган, сәнгатьне югары күтәргән әдәби концепция милләт хәле белән бәйләп куела.Татарда сәнгатьне, мәхәббәтне тыю мохит кысалары, чикләүләре кебек аңлашыла: “Менә тормыш! Менә сиңа хөррияте шәхсия! Яшәргә уйлыйсың, бәхет эзлисең! Бар да әрәмгә! Бар да юкка!.. Имеш музыка хәрам! Җыр хәрам! Матурлык гөнаһ! Матурлык белән тәләззез хәрам! Матурлык алдында сәҗдә итү көферлек! Соң, Илаһым, алай булгач, безгә ник мондый җан бирдең?..” Һ.б. Зыяның соңгы сүзләре бу фәлсәфәне тагын бер тапкыр кабатлый: “Мин кулыма музыка коралы алып уйный башласам, шул минутта гүя эчем бөтен татарлык куәтен үзенә җыя…Шул вакыт мин, бәлки хыялыйлыгымнандыр, язмыш уң биреп гомер вәфа итсә, музыкам белән татарның аслы рухын уятырмын, күгәргән йөрәген сафлармын һәм авыр язмышына бер үзгәреш бирермен, томанлы вә караңгы хәятына бер нур тудырырмын кебек хис итә башлыйм..” Ягъни милли фәлсәфә болай дәвам итә: үсештән туктаган милләтләрне сәнгать уята, кузгата, алга җибәрә ала.

Г. Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романындагы мәгърифәтчел идеяләрнең чагылышын анализлау түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирде:

1.Бу чорда мәгърифәтчелеккә хас структураларның тамырдан үзгәрүе, трансформацияләнүе зур жанрлар мисалында да күзәтелә. Милли үзаң үсү, милләт язмышы өчен борчылу татар әдәбиятын колачлап ала да милләткә хезмәт итү, әдәби сүзнең көченә, акыл-фикергә ышану һ.б. мотивларны беренче планга этәрә.

2.Татар әдәбияты XX гасырга мәгърифәтчелек әдәбияты булып килеп керә, мәгърифәтчелек реализмнан тәнкыйди реализмга һәм романтизмга таба хәрәкәт итә. Әдәбиятның төп сурәтләү объекты булган кешене тәрбия һәм мохит җимеше итеп караудан узып , әдипләр кеше аңындагы логик – рациональ якын килү юлы белән генә аңлатып булмый торган якларны да игътибар үзәгенә ала башлыйлар. Кешенең аңхаләте, фикер агышы, хис көчеше әдәбиятта чагылдыру өчен мөһим табыла.

3. Фәнни хезмәттә галимә

Д.Заһидуллинаның XX гасыр башы фәлсәфи әсәрләрне анализлауга караган өйрәтмәләрен файдалану Г. Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романын яңача шәрехләргә ярдәм итте. Әлеге әсәргә яңа күзлектән карау әдипнең дөнья әдәбиятына керткән өлешен дә яңадан раслау булыр иде.

Кулланылган әдәбият исемлеге

1. Газиз Г. Яшь әдәбиятыбызда “Яшь йөрәкләр” // Аң. – 1913. - №11

2. Галимуллин Ф.Г. Эзләнү вакыты. – Казан: Мәгариф, 2005.

3. Ганиева Р.К. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань, 2002

4. Заһидуллина Д. Дөнья сурәте үзгәрү: XX гасыр башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография / Д.Ф.Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2006

5. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002.

6. Нигъматуллина Ю.Г Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. – Казань, 1997.

7. Теория литературы. Литературный процесс. Т. IV.

8. Федоров А.А. Введение в теорию и историю культуры: Словарь.- Уфа, 2003.

9. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов: тормыш һәм иҗат юлы.- Казан, 1964.